“АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ”

# Чишмә башы

№ 3
Ноябрь
2025 ел

**Әти-әниләр һәм балалар өчен татарча гәҗит**

## «АРЧА 1 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» - "ИҢ ЯХШЫ БИЛИНГВАЛЬ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ" РЕСПУБЛИКА БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕСЕ!

**"Иң яхшы билингваль балалар бакчасы 2025" республика конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы булып узды. Безнең балалар бакчасы да 500 000 сумлык грант иясе булды. Бергә-бергә эшләгәндә генә ике дәүләт телен дә тигез дәрәҗәдә үстерергә мөмкин. Бу казаныш педагогик коллективның югары профессиональлеген, уку процессын оештыруда креативлыгын һәм балаларның икетелле тәрбия программасын гамәлгә ашыруда актив катнашуын ассызыклый. Педагогларның, ата-аналарның һәм балаларның уртак тырышлыгы балаларның гармонияле үсешенә ярдәм итә торган уникаль белем бирү мохите тудырды.**









## БЕЗ— «ТАТАРСТАН– ЯҢА ГАСЫР» КАНАЛЫНДА

**27 нче ноябрь көнне бакчабыз мөдире Шакирова Алсу Фаридовна белән татар теле тәрбиячесе Камалиеа Гөлназ Рәисовна «Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалында эшләп килүче “Манзара” тапшыруына махсус кунак буларак чакырылдылар. Алар «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» бәйгесе кысаларында эшләп килүче проект турында, балалар бакчасы белән ата-аналарның бердәм эшчәнлеге хакында сөйләделәр.**

## ӘНИЕМНЕҢ ҖЫЛЫ КОЧАГЫ








**Әни… Әлеге кыска гына сүз үз эчендә күпме наз, йөрәк җылысы һәм яратуны саклый. Аны әйткән саен күңел йомшара, ишеткән саен дөнья ямьләнә. Ноябрь аенда Әниләр көне уңаеннан бик күп төрле музыкаль чаралар үткәрелде. Бәйрәмнәрдә балалар әниләренә багышлап шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар, матур биюләр күрсәттеләр. Шулай ук әниләр белән берлектә күңелле уеннарда катнаштылар. Бәйрәмнәр күңел күтәренкелеге белән бик күңелле үтте. Балалар соңыннан әниләренә үзләре әзерләгән бүләкләрен тапшырдылар. Әниләргә дә, балаларга да бәйрәм иртәләре бик ошады.**

## БЕЗНЕҢ УҢЫШЛАРЫБЫЗ



**Әниләр көне кысалыгында бакчабызда «Әни белән мин» дип аталган бик матур бәйге булып узды. Бәйгедә әниләр үзләренең балалары белән чыгыш ясадылар, осталык дәресләре күрсәттеләр һәм төрле яктан талантлы булуларын дәлилләделәр. Олы йөрәкле әниләребезгә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Сезгә озын гомер, бәхет, сәламәтлек телибез. Шушы бәйрәм көне күңелегезгә шатлык, тәнегезгә сихәтлек, өегезгә иминлек алып килсен!**



**Район күләмендә үткәрелгән «Әни белән бергә» бәйгесендә мәктәпкә әзерлек төркеменнән Хайдарзянова Гүзәл әнисе Диләрә ханым белән 1 нче урынга лаек булдылар. Бакчабызның данын яклап, күңелләрен балаларга ачып салган әлеге гаиләгә алда тагын да зур уңышлар телибез. Котлыйбыз**




**Районкүләмендә үткәрелгән осталык дәресләре бәйгесендә укытучы-логопед Бахтиярова Илюса Ильсуровна 1 нче урын алды. Тырыш, иҗади педагогыбызга киләчәктә зур уңышлар телибез!**

**Гәҗитне татар теле тәрбиячесе Камалиева Гөлназ Рәис кызы әзерләде**